МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.10.2020 г.Казань № 735

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 11 ноябрендә 6935 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 16 октябрендәге 735 номерлы боерыгы белән расланган

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 21 июлендәге «Даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 490 санлы боегыры белән расланган даими рәвештә кеше каравына (ярдәменә, күзәтүенә) мохтаҗ булган 18 яшькә кадәрге инвалид балаларга өстәмә айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 7 июнендәге 317 санлы, 2017 елның 23 мартындагы 171 санлы, 2017 елның 8 июнендәге 349 санлы, 2018 елның 7 маендагы 351 санлы, 2018 елның 18 сентябрендәге 885 санлы, 2019 елның 24 июнендәге 494 санлы, 2019 елның 5 ноябрендәге 919 санлы, 2020 елның 4 апрелендәге 257 санлы, 2020 елның 14 июлендәге 516 санлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә):

2 бүлектә:

2.6 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәге белешмәләрне раслаган документлар алына:

баланың тууын (уллыкка алынуын) дәүләт теркәве турында белешмәләр - баланың (балаларның) туу (уллыкка алыну) турында акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта (вәкаләтле органнардан);

шәхси исәп-хисап счетының иминият саны;

инвалид баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтүгә сәләтен өченче дәрәҗә чикләү турында тамга булганда инвалид кешене реабилитацияләүнең яисә абилитацияләүнең шәхси программасыннан (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

инвалид балага опека (попечительлек) билгеләү, инвалид баланы тәрбиягә бала алган гаиләгә тапшыру, инвалид баланың тулы дәүләт тәэминатында булуы турында (җирле үзидарә органнарыннан);

мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе яки ата-ана хокукларын чикләве турында (җирле үзидарә органнарыннан);

даими яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән затлар турында (вәкаләтле органнардан);

законлы вәкилнең хезмәткә сәләтсез гражданнарны караучы затларга билгеләнгән компенсация түләвен алуы раслаучы (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

эшсезлек буенча пособиеләрнең барлык төрләрен түләүләр һәм эшсезләргә башка түләүләр алуы (алмавы) турында (халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләрендә);

пенсияне, компенсация түләүләрен (хезмәткә сәләтсез гражданнарны тәрбияләп торган эшләмәүче хезмәткә сәләтле затларга компенсация түләүләреннән тыш) һәм Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсионерларга айлык өстәмә матди тәэмин итүләрне алу һәм аларның күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

физик затларның алынган керемнәре турында (Федераль салым хезмәтеннән);

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы (алга таба - Россия Эчке эшләр министрлыгы) тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында;

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы (алга таба - Россия Оборона министрлыгы) тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында;

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының социаль яклау органнары яисә территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала табу буенча пособие күләме турында белешмәләр (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының социаль яклау органнарыннан яисә территориаль органнарыннан);

вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча пособие турында (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарыннан);

Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының социаль яклау органнары яисә территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелекнең иртә срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга бер мәртәбә бирелә торган пособие күләме турында белешмәләр (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының социаль яклау органнарыннан яисә территориаль органнарыннан);

Россия Федерация Социаль иминиятләштерү фондының социаль яклау органнары яисә территориаль органнары тарафыннан түләнә торган баланы карау буенча ай саен түләнә торган пособие күләме турында белешмәләр (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарыннан яки социаль яклау органнарыннан);

социаль яклау органнары тарафыннан балага түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында (социаль яклау органнарыннан);

социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган өстәмәләр һәм әлеге пунктчада күрсәтелгән социаль түләүләрнең барлык төрләренә өстәмә түләү күләме турында белешмәләр (социаль яклау органнарыннан);

Россия Федерациясе, аның субъектларындагы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль

яклау органнары тарафыннан түләнә торган башка социаль түләүләр күләме турында белешмәләр (социаль яклау органнарыннан);

иминиятләштерелгән гражданнарга производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре турында, әгәр медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча аларны алу хокукы булган зат һөнәри хезмәткә сәләтен югалтса яисә, иминият очрагы иминиятләштерелгән затның үлеме нәтиҗәсендә барылкка килсә, аларны алу хокукына ия булга нзатларга (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр (вәкаләтле оешмалардан).

Гариза бирүче югарыда күрсәтелгән белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.

Күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон формада алынырга һәм әлеге Регламентта, 2.5 пунктта каралган тәртиптә билгеләнгәнчә тапшырылырга мөмкин.

Гариза бирүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмау гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуы өчен нигез булып тормый.

Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәткәндә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә үтәү каралмаган гамәлләрне тормышка ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирү;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүмат бирүне;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, беренче тапкыр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны»;

2.14 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат

стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 2 абзацында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгән объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен инвалидларга түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектка һәм дәүләт хезмәте күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-нокталы шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын раслый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы "Йөртүче этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында" боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтен алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә башка төрле ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-ноктлы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

«Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 14 ст., 15 ст»;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 июлендәге 527 номерлы «Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану шартларын тәэмин итү, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» боерыгы.».

3 бүлектә:

3.4.1 пунктчаның уникенче абзацында «(әлеге пунктчаның таләбе 2020 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Бүлекчәдә айлык акчалата түләү билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, үзәк бүлеге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада белешмәләр бирү турында запрослар җибәрә:

Татарстан Республикасыннан читтә теркәлү актын алган очракта, балаларның тууын (уллыкка алынуын) дәүләт теркәвенә алу турында һәм балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында - вәкаләтле органга;

Россия Федерациясе Пенсия фондында шәхси исәп-хисап счетының иминият саны турында;

инвалид баланы тернәкләндерүнең яисә инвалид кешене реабилитацияләүнең шәхси программасыннан, инвалид баланың үз-үзенә хезмәт күрсәтүгә сәләтен өченче дәрәҗә чикләү турында тамга булганда - Россия Федерациясе Пенсия фондында-инвалид кешене реабилитацияләүнең яисә реабилитацияләүнең шәхси программасыннан;

инвалид балага опека (попечительлек) билгеләү, инвалид баланы тәрбиягә бала алган гаиләгә тапшыру, инвалид баланың тулы дәүләт тәэминатында булуы турында-җирле үзидарә органнарына;

вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособие күләме турында-Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органына;

мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында - җирле үзидарә органнарына;

Россия Оборона министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында - Россия Оборона министрлыгына;

медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, һөнәри эшкә яраклылык югалган булса, медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, иминләштерелгән затның үлеме иминият очрагы килеп туган очракта, җитештерүдәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча айлык иминият түләүләре күләме турында - Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнарына;

вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособие, йөклелек һәм бала табу буенча пособиеләр, шулай ук йөклелекнең иртә срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие күләмнәре турында - Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органына;

бала карау буенча айлык пособие күләме турында - Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органына;

Россия Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында - Россия Эчке эшләр министрлыгына;

законлы вәкилнең хезмәткә сәләтсез гражданнарны караучы затларга билгеләнгән компенсация түләвен алуы турында - Россия Федерациясе Пенсия фондында;

физик затларның алынган керемнәре турында - Федераль салым хезмәтенә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр - вәкаләтле оешмаларга.

даими яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә яшәүче затлар турында - вәкаләтле органнарга.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көннән гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында запрос.».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 28 июлендәге 516 номерлы «Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга, уку дәвамында ике ата-анасын да, яки бербәндер ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга пособие, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 ел № 317, 22.06.2017 ел № 406, 07.05.2018 ел № 349, 18.09.2018 ел № 885, 24.06.2019 ел № 493, 12.11.2019 ел № 992, 25.02.2020 ел № 119, 14.07.2020 ел № 516 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән

мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга, уку дәвамында ике ата-анасын да, яки бербәндер ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга пособие, субсидия, стипендия билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 Бүлекнең 1.5 пунктында «нормативлы» сүзен «норматив» сүзенә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.5 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2.6 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы алтынчы абзацта «(әлеге абзацның таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 2 абзацында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгән объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен инвалидларга түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектка һәм дәүләт хезмәте күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен

алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-ноктaлы шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын раслый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы "Йөртүче этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында" боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтен алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә башка төрле ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-ноктaлы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

«Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 14 ст., 15 ст.»;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 июлендәге 527 номерлы «Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану шартларын тәэмин итү, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» боерыгы.».

3 бүлектәге 3.3.2.1 пунктчаның дүртенче абзацында «(әлеге абзацның таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә)» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 2012 елның 20 июнендәге 445 номерлы «Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып,

кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министырлыгының 04.09.2014 ел № 485, 07.06.2016 ел № 317, 11.07.2016 ел № 399, 08.06.2017 ел № 351, 07.05.2018 ел № 352, 18.09.2018 ел № 885, 07.05.2019 ел № 324, 14.11.2019 ел № 1011, 25.03.2020 ел № 193, 14.07.2020 ел № 517 боерыкларында кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Пенсия белән Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан тәэмин ителүче, Чечен Республикасында һәм Төньяк Кавказның аның янәшәсендә үк урнашып, кораллы низаг зонасына кертелгән территорияләрендә халыкара булмаган кораллы низаг шартларында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, шулай ук Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр барышында бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һәлак булган (үлгән), хәбәрсез югалган, инвалид булып калган хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре һәм кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләре балаларының җәйге сәламәтләндерү ялын уздыруга пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.14 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 2 абзацында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгән объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен инвалидларга түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектка һәм дәүләт хезмәте күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-ноктал шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын раслый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы "Йөртүче этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында" боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтен алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә башка төрле ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-ноктал Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

«Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 14 ст., 15 ст.»;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 июлендәге 527 номерлы «Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану шартларын тәэмин итү, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» боерыгы.».